| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2025 Красный Бор авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный бор авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»гы 2025 елның 31 октябрендә кабул ителгән № 1 карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Красный Бор авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында»гы 2025 елның 31 октябрендә кабул ителгән 1нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:
1) карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «гамәлдәге законнар нигезендә, таянып» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы рәсми сайтында түбәндәге

веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Муниципаль берәмлек башлыгы Е. А. Яковлева

Совет Красноборского сельского поселения Красный Бор авыл җирлеге Советы ИНН 1601002484